СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2021 № 15/3

На № ________ от ____________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), район Уставының 30 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 25/5 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе                                                    Ф.М.Камаев

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 14 декабрендәге 15/3 номерлы карарына кушымта

**Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгының, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләме**

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 34 967 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 31 469 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31 469 |